СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru


Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «12» декабреннән № 29-230

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 17-134 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының структурасына һәм чик санына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25 номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча совет каршындагы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары структурасын камилләштерү мәсьәләләре буенча эшче төркем утырышы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымтага нигезләнеп, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең структурасын һәм иң чик санын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 17-134 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карарына «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының структурасы һәм аның чик саны» дигән 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http//pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының
2021 елның 29 декабрендәге
17-134 номерлы карарына
2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының түбәндәге карарлары редакциясендә:
2022 елның 08 апрелендәге 20-164 номерлы;
2022 елның 03 августындагы 25-193 номерлы;
2022 елның 08 сентябрендәге 26-204 номерлы;
2022 елның 12 декабрендәге 29-230 номерлы)

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының структурасы һәм чик саны

| № т/б | Вазыйфа исеме | Берәмлекләр саны |
|---|---|---|
| 1. | Җитәкче | 1 |
| 2. | Җитәкченең беренче урынбасары (икътисад буенча) | 1 |
| 3. | Җитәкче урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча) | 1 |
| 4. | Җитәкче урынбасары (инфраструктур үсеш буенча) | 1 |
| 5. | Эшләр белән идарә итүче | 1 |
| 6. | Җитәкче ярдәмчесе (мобилизация эшләре буенча) | 1 |
| Мәгариф бүлеге | | |
| 7. | Башлык | 1 |
| 8. | Башлык урынбасары | 1 |
| 9. | Баш белгеч | 1 |
| Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | | |
| 10. | Башлык | 1 |
| 11. | Баш белгеч | 1 |
| Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге | | |
| 12. | Башлык | 1 |
| 13. | Баш белгеч | 1 |
| 14. | Әйдәп баручы белгеч | 1 |
| Мәдәният бүлеге | | |
| 15. | Башлык | 1 |
| 16. | Тәрҗемәче (хезмәткәр) | 1 |
| Икътисад һәм муниципаль заказ бүлеге | | |
| 17. | Башлык | 1 |
| 18. | Башлык урынбасары | 1 |
| 19. | Баш белгеч | 1 |
| 20. | Әйдәп баручы белгеч | 1 |
| Опека һәм попечительлек бүлеге | | |
| 21. | Башлык | 1 |
| 22. | Баш белгеч | 1 |
| 23. | Әйдәп баручы белгеч | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| Архив секторы | | |
| 24. | Мөдир | 1 |
| Мәгълүмат белән тәэмин итү һәм мәгълүмати иминлек секторы | | |
| 25. | Мөдир | 1 |
| ГХАТ секторы | | |
| 26. | Мөдир | 1 |
| Балигъ булмаганнар эшләре һәм административ практика секторы | | |
| 27. | Баш белгеч (балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең җаваплы секретаре) | 1 |
| 28. | Әйдәп баручы белгеч (балигъ булмаганнар арасында гаилә җитешсезлекләрен һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча инспектор) | 1 |
| 29. | Административ комиссия секретаре | 1 |
| Категориядән тыш | | |
| 30. | Автомобиль йөртүче | 4 |
| 31. | Җитәкче секретаре | 2 |